МИНИСТЕРСТВО
ЗДРАВООХРАНЕНИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.05.2022 г. Казань № 1443

Бәяләү бите формасын раслау турында

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 19.1 статьясындагы 8 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 июнендәге 852 номерлы карары белән расланган Медицина эшчәнлеген лицензияләү турында («Сколково» инновацион үзәге территориясендә медицина оешмалары һәм сәламәтлек саклауның хосусый системасына керә торган башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган күрсәтелгән эшчәнлектән тыш) нигезләмәнең 3 пункты «б» пунктчасы нигезендә боерам:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан лицензия алырга дәгъва кылучының яисә лицензиатның медицина эшчәнлеген гамәлгә ашырганда («Сколково» инновацион үзәге территориясендә медицина оешмалары һәм сәламәтлек саклауның хосусый системасына керә торган башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган күрсәтелгән эшчәнлектән тыш) лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләү үткәрелә торган кушымта итеп бирелә торган бәяләү бите формасын расларга.

2. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары В.В.Виниченкога йөкләргә.

Министр М.Н.Садыйков

А.В.Кочнев,
(843)236-65-72

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы белән расланган
19.05.2022 № 1443

Форма

**Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның медицина эшчәнлеген гамәлгә ашырганда лицензия таләпләренә («Сколково» инновацион үзәге территориясендә медицина оешмалары һәм сәламәтлек саклауның хосусый системасына керә торган башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган күрсәтелгән эшчәнлектән тыш) туры килү-килмәвен бәяләү үткәрелә торган бәяләү бите.**

1. Лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның лицензия таләпләренә[1] туры килүен бәяләү формасы, теркәлү номеры һәм лицензия бирү турында гаризаны теркәү датасы (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү):

____________________________________________________________

____________________________________________________________

2. Тулы яисә кыскартылган исеме (булган очракта), һәм юридик затның оештыру-хокукый рәвеше, аның урнашу урыны адресы, юридик затның төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН), индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), яшәү урыны адресы, индивидуаль эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры (ОГРНИП):

____________________________________________________________

____________________________________________________________

3. Медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынын (урыннарын) идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган адрес (адреслар) һәм (яисә) башка белешмәләр:

____________________________________________________________

4. Бәяләү битен тутыру белән лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләүне үткәрү урыны (урыннары): ____________________________________________________________

____________________________________________________________

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кабул ителгән лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләү үткәрү турындагы карар реквизитлары:

____________________________________________________________

____________________________________________________________

6. Лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләүче һәм бәяләү бите тутыручы Министрлыкның вазыйфаи заты вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта):

____________________________________________________________

____________________________________________________________

7. Лицензия алырга дәгъва кылучының яки лицензиатның лицензиат таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында таныкларга тиешле контроль сораулар исемлеге:

| № п/п | Лицензия таләпләре эчтәлеген чагылдыра торган контроль сораулар исемлеге | Лицензия таләпләре билгеләнгән структур | Контроль сораулар исемлегендә булган сорауларга җаваплар | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | әйе | юк | кулланышка | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | бирәмлекләрен күрсәтеп, норматив хокукый актлар реквизитлары | | | туры килми | |
| I. Лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның лицензион таләпләргә документар бәяләү формасында туры килүе | | | | | | |
| 1. | Лицензия бирү яки лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза, шул исәптән электрон документ формасында яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) һәм башка мәгълүмати системаларның бердәм порталыннан файдалану юлы белән бирелгән гариза, билгеләнгән формага туры киләме, тулы күләмдә тутырылганмы? | «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон №99-ФЗ )13 статьясындагы 1 өлеш, 3 өлеш, 18 статьясындагы 3 [1] өлеше,19 [1] статьясындагы 4 өлеше, 2021 елның 1 июне № 852 [2] Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Медицина эшчәнлеген лицензияләү турында («Сколково» инновацион үзәге территориясендә медицина оешмалары һәм сәламәтлек саклауның хосусый системасына керә торган башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган күрсәтелгән эшчәнлектән тыш) нигезләмәнең 8 һәм 11 пунктлары (алга таба –Нигезләмә) | | | | |
| 2. | Гаризада күрсәтелгән лицензия алырга теләүче яки лицензиат турында белешмәләр юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында, аккредитацияләнгән филиалларның, чит ил юридик затларының дәүләт реестрында, Шәхси | Федераль законның №99-ФЗ 19 [1] статьяның 4 өлеше | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында һәм башка федераль мәгълүмат ресурсларында күрсәтелгән белешмәләргә туры киләме? | | | | | |
| 3. | Лицензия алырга дәгъва кылучының/лицензиатның милек хокукында яки башка законлы нигездә гаризада күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле бина, төзелмәләр, корылмалар һәм (яки) бүлмәләр бармы? | Нигезләмәнең 5 пунктындагы «а» пунктчасы, 8 пунктның «а» пунктчасы | | | | |
| 4. | Лицензия алырга дәгъва кылучының/лицензиатның милек хокукында яки башка законлы нигездә, гаризада күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле медицина әйберләре (җиһазлар, аппаратлар, приборлар, инструментлар) бармы? | Нигезләмәнең 5 пунктындагы «б» пунктчасы, 8 пунктның «б» пунктчасы | | | | |
| 5. | Лицензия алырга дәгъва кылучының (лицензиатның) гаризада күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм (яки) бүлмәләрнең санитар кагыйдәләренә туры килүе турында бирелгән санитар-эпидемиологик бәяләмә бармы? | Нигезләмәнең 8 пунктындагы «в» пунктчасы | | | | |
| 6. | Лицензия алырга дәгъва кылучы (лицензиат) белән хезмәт килешүләре төзегән хезмәткәрләрнең лицензия алырга дәгъва кылучы (лицензиат) күрсәткән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен тиешле белеме һәм белгеч аккредитация узганмы яки белгеч сертификаты бармы? | Нигезләмәнең 5 пунктындагы «в» пунктчасы, 8 пунктның «д» пунктчасы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) белән медицина әйберләренә (җиһазларга, аппаратларга, приборларга, инструментларга) техник хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәт килешүләре, тиешле һөнәри белем һәм (яки) квалификация, яисә тиешле эшчәнлекне тормышка ашыруга лицензиясе булган оешма белән килешү төзелгәнме? | Нигезләмәнең 5 пунктындагы «г» пунктчасы, 8 пунктның «е» пунктчасы | | | | |
| 8. | Теркәлгән документлар исемлеге тәкъдим ителгәнме һәм расланган формага туры киләме? | Нигезләмәнең 8 пунктындагы «з» пунктчасы | | | | |
| 9. | Гариза күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле медицина әйберләре (җиһазлар, аппаратлар, приборлар, инструментлар), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 декабрендәге №1416 [3] карары белән расланган Медицина эшләнмәләрен дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә теркәлгәнме? | Нигезләмәнең 8 пунктындагы «г» пунктчасы; 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның [4] 38 статьясындагы 4 өлеше; | | | | |
| 10. | Донор канын һәм (яисә) аның компонентларын клиник куллануны гамәлгә ашырырга планлаштыра торган медицина оешмасы, лицензияләнә торган эшчәнлек төренең бер өлеше буларак трансфузиологияне күрсәтеп, медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе бармы? | Нигезләмәнең 5 пунктындагы «е» пунктчасы, 2012 елның 20 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законның [5] 16 статьясы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 11. | Донор канын һәм (яисә) аның компонентларын әзерләүне һәм саклауны гамәлгә ашырырга планлаштыра торган медицина оешмасы, лицензияләнә торган эшчәнлек төренең өлешләре сыйфатында донор канын һәм (яисә) аның компонентларын хәзерләү һәм саклау күрсәтеп, медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе бармы | № 125-ФЗ Федераль законның 15 статьясындагы 2 өлеше, Нигезләмәнең 5 пунктындагы «е» пунктчасы | | | | |
| 12. | Кеше органнарын һәм (яисә) тукымаларын алу һәм әзерләү буенча, шулай ук аларны трансплантацияләү буенча эшләрне (хезмәтләрне) гаризада күрсәткәндә медицина оешмасы сәламәтлек саклауның дәүләт яисә муниципаль системасына кергәнме? | Россия Федерациясе Законының 1992 елның 22 декабрендәге 4180-1 номерлы Карарының 5 пунктындагы «е» пунктчасы, 4 статьясы [6] | | | | |
| 13. | Медицина оешмасы, шәхси эшкуар (алга таба - ИП) тарафыннан медицина оешмасы турында белешмәләр медицина оешмаларының федераль реестрында урнаштырыганмы? | Нигезләмәнең 5 пунктындагы «ж» пунктчасы, 8 пунктның «ж» пунктчасы | | | | |
| 14. | Медицина оешмасы, ИП тарафыннан медицина хезмәткәрләре турында белешмәләр медицина хезмәткәрләренең федераль регистрында урнаштырылганмы? | Нигезләмәнең 5 пунктындагы «ж» пунктчасы, 8 пунктның «ж» пунктчасы | | | | |
| II. Лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның лицензия таләпләренә күчмә бәяләү формасында туры килүе | | | | | | |
| 15. | Юридик затның, шәхси эшкуарның милек хокукында яки башка законлы нигездә бирелгән эшләрне(хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле бина, төзелмә, корылма һәм | Федераль законның №99-ФЗ 19 [1] статьясындагы 5 өлеше, Нигезләмәнең 5 пунктындагы «а " пунктчасы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | (яки) бүлмә бармы? | | | | | |
| 16. | Юридик затның, шәхси эшкуарның милек хокукында яки ия булу һәм файдалану хокукын күздә тоткан башка законлы нигездә гаризада күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле медицина әйберләре (җиһазлар, аппаратлар, приборлар, инструментлар) бармы? | **Федераль законның №99-ФЗ 19 [1]** статьясындагы 5 өлеше, Нигезләмәнең 5 пунктындагы «б» пунктчасы | | | | |
| 17. | Дәүләт сәламәтлек саклау системасының яисә муниципаль сәламәтлек саклау системасының медицина оешмасында штат расписаниесе бармы? | 323-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 2 өлешенең 7 пункты, Нигезләмәнең 5 пунктындагы «д» пунктчасы | | | | |
| 18. | Штат расписаниесендә гариза күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне)үтәү өчен кирәкле медицина оешмасының структур бүлекчәләре бармы? | Нигезләмәнең 5 пунктындагы «д» пунктчасы, 14 статьясындагы 2 өлешенең 7 пункты, 323-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 2 өлеше | | | | |
| 19. | Медицина оешмасының штат расписаниесендә гариза күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле медицина хезмәткәрләренең вазыйфалары бармы? | Нигезләмәнең 5 пунктындагы «д» пунктчасы, 14 статьясындагы 2 өлешенең 7 пункты, 323-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 2 өлеше | | | | |
| 20. | Донор канын һәм (яисә) аның компонентларын клиник куллану максатларында медицина оешмасында структур бүлекчәләр сыйфатында донор канын һәм (яисә) аның компонентларын саклауны, статистик исәпкә алуны, шул исәптән донор канын һәм (яисә) аның компонентларын трансфузиядән (күчергәннән) соң барлыкка килгән | Нигезләмәнең 5 пунктындагы «е» пунктчасы, № 125-ФЗ Федераль законның 16 статьясы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | реакцияләргә һәм өзлегүләргә карата махсуслаштырылган кабинетлар яисә бүлекләр булдырылганмы? | | | | | |
| 21. | Күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле медицина әйберләре саны җиһазландыру стандартларына туры киләме? | 323-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 2 өлеше, Нигезләмәнең 5 пунктындагы «б» пунктчасы | | | | |
| 22. | Квалификация таләпләре белән каралган һәм гаризада күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен медицина хезмәткәрләренең белеме бармы? | Нигезләмәнең 5 пунктындагы «в» пунктчасы | | | | |
| 23. | Күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен медицина хезмәткәрләре белгеч аккредитациясе яисә белгеч сертификаты бармы? | Нигезләмәнең 5 пунктындагы «в» пунктчасы | | | | |
| 24. | Юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан гариза биргән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле хезмәткәрләр белән хезмәт килешүләре яки тиешле эшчәнлекне тормышка ашыруга лицензиясе булган оешма белән килешү төзелгәнме? | Нигезләмәнең 5 пунктындагы «г» пунктчасы | | | | |

«Медицина эшчәнлеген лицензияләү турында («Сколково» инновацион үзәге территориясендә медицина оешмалары һәм сәламәтлек саклауның хосусый системасына керә торган башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган күрсәтелгән эшчәнлектән тыш) һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 июнендәге 852 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә

лицензия таләпләренә лицензиягә дәгъва кылучының/лицензиатның туры килүе/туры килмәве (тиешлесенә астына сызарга) билгеләнгән.

________________________________________ ____________________

(бәяләүне үткәргән һәм бәяләү битен тутырган вазыйфаи зат) (имза)

Бәяләү битен тутыру датасы

«___» ___________ 20___ ел.

[1]«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында»2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 19 [1] статьясындагы 3 өлеше.
[2]«Медицина эшчәнлеген лицензияләү турында («Сколково» инновацион үзәге территориясендә медицина оешмалары һәм сәламәтлек саклауның хосусый системасына керә торган башка оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган күрсәтелгән эшчәнлектән тыш) һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 июнендәге 852 номерлы карары.
[3] «Медицина эшләнмәләрен дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 декабрендәге 1416 номерлы карары.
[4]«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында»2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон.
[5]«Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында» 2012 елның 20 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон
[6]«Кеше органнарын һәм (яисә) тукымаларын трансплантацияләү турында»1992 елның 22 декабрендәге 4180-1 номерлы Россия Федерациясе Законы.